# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**16 октябрь 2022 ел** **№ 1**

Татарстан Республикасы Азнакай
муниципаль районы Әгерҗе авылында
гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлеге Уставы нигезендә 2022 елның 16 октябрендә түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре буенча гаражданнар җыенының йомгаклау протоколы төзелде:

«Сез, 2023 елда 1 төркем инвалидлар, гаилә әгъзалары өлешчә мобилизациягә чакырылган гражданнарыннан, түләүне бер тапкыр киметеп 80 яшьтән өлкән пенсионерлар өчен 500 сум күләмендә Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлеге Әгерҗе авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 650 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:

- Әгерҗе авылында җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту (юлларга вак таш сатып алу, таш салу, таш җәю, Г.Ахметова урамы, килешү буенча эш өчен түләү);
-җирлек территорияләрен төзекләндерүне оештыру (территорияне механикалаштырып, триммер белән чабу буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, килешү буенча эшләр, ягулык-майлау материаллары һәм триммер өчен запас частьләр сатып алу);
- Әгерҗе авылы мәдәният йорты территориясена койма кую өчен материаллар сатып алу, койманы кую;
- бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү (бүләк, сувенир продукция сатып алу, «Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне», «Корбан бәйрәме», «Яңа ел " бәйрәм чараларын үткәрү буенча хезмәт күрсәтү, спорт чаралары.»);
- ритуаль хезмәтләрне оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту;
- трактор йөртүчесенә хезмәте өчен түләү.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия 368 гражданнар җыенында катнашучы теркәлгән, халык җыенында катнашып тавыш биргән гражданнар саны 251.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«РИЗА» позициясе өчен 237, «КАРШЫ» позициясе өчен 13 гражданнар җыенында катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлеге Әгерҗе торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре–гамәлдә (дөрес) дип таныргa.

2. Түбәнәге сорау буенча карарны кабул ителгән дип таныргa:

«Сез, 2023 елда 1 төркем инвалидлар, гаилә әгъзалары өлешчә мобилизациягә чакырылган гражданнарыннан, түләүне бер тапкыр киметеп 80 яшьтән өлкән пенсионерлар өчен 500 сум күләмендә Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлеге Әгерҗе авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 650 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:

- Әгерҗе авылында җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту (юлларга вак таш сатып алу, таш салу, таш җәю, Г.Ахметова урамы, килешү буенча эш өчен түләү);

-җирлек территорияләрен төзекләндерүне оештыру (территорияне механикалаштырып, триммер белән чабу буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, килешү буенча эшләр, ягулык-майлау материаллары һәм триммер өчен запас частьләр сатып алу);

- Әгерҗе авылы мәдәният йорты территориясена койма кую өчен материаллар сатып алу, койманы кую;

- бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү (бүләк, сувенир продукция сатып алу, «Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне», «Корбан бәйрәме», «Яңа ел " бәйрәм чараларын үткәрү буенча хезмәт күрсәтү, спорт чаралары.»);

- ритуаль хезмәтләрне оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту;

- трактор йөртүчесенә хезмәте өчен түләү.

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә

- Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru,

- Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru),

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, Әгерҗе авылы, Г.Ахметова урамы, 1 йорт адресы буенча, Әгерҗе авылы, С.Хаким урамы, урам чатында, Әгерҗе авылы, Г.Гафиятуллина урамы, 10 йорт белән 23а йорты арасында урнашкан Әгерҗе авыл җирлеге мәгълүмати стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Әгерҗе авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Әгерҗе авыл җирлеге башлыгы Н.Н.Хәсәнов